**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12417**
**22.12.2023**

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2593 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 634 482,59 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 518 410,00 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.»;

2) кушымтада:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында «2023» графасында «618 892,51» цифрларын «597 662,59» цифрларына алмаштырырга;

- 3 бүлектә «УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту» юлында «Финанслау һәм финанслау чыганаклары 2023» баганасында «618 892,51» цифрларын «597 662,59» цифрларына алмаштырырга;

4) 4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 634 482,59 мең сум күләмендә

муниципаль бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 518 410,00 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов